**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ ______________ КАРАР __________

Актаныш муниципаль районының «Актаныш автотранспорт хуҗалыгы» муниципаль унитар предприятиесе Уставына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль закон, «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 27 августындагы 176 номерлы карары белән расланган Актаныш муниципаль районы «Актаныш автотранспорт хуҗалыгы» муниципаль унитар предприятиесе Уставына (алга таба Уставы) үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Актаныш муниципаль районы «Актаныш автотранспорт хуҗалыгы» муниципаль унитар предприятиесе директоры Шакиров Айзат Зиннур улына, гариза, башка документлар имзаларга, кирәкле гамәлләр кылырга, закон нигезендә гамәлгә кую документларына үзгәрешләр кертүне тәэмин итәргә.
3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.А.Ильясов

Актаныш муниципаль районының «Актаныш автотранспорт хуҗалыгы» муниципаль унитар предприятиесе Уставына үзгәрешләр кертү

«Предприятие эшчәнлегенең максатлары, предметы һәм төрләре» 5 бүлегендәге 5.2 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

- гражданнар төзелеше биналарының һәм корылмаларының барлык төрләрендә электр техник системалары урнаштыру;

- электр үткәргечләр һәм электр арматуралары монтажы,телекоммуникацияләр, компьютер челтәре һәм кабельле телевидение үткәргечләре, шул исәптән элемтә линияләрен дә кертеп, барлык типтагы антенналар, яктырту системаларын, янгын сигнализациясен, автомобиль юлларында урамнарны яктырту һәм башка электр җиһазларын, җир өсте электр транспортын һәм электр-техник сигнал җиһазларын энергия белән тәэмин итү системаларын, аэропортларның һәм космодромнарның очып китү полосаларын, кояш энергиясенең электр коллекторларын яктыртуны да кертеп;

- электр приборларын, кодлы бикләрне, домофоннарны һәм башка җиһазларны тоташтыру өчен электр челтәрләре китерү эшләрен башкару, шул исәптән плинтуслы җылытуны да кертеп;

- мәдәни мирас объектларында электр белән тәэмин итү системаларын урнаштыру.

- мәдәни мирас объектларында инженерлык системаларын һәм җайланмаларын урнаштыру.